

Никадәр кvп янгырлар яуса да гомбәләр саны әлләни кvп тvгел. Әмма без аны жыюдан туктамыйбыз. Үткән ял коннәре урманда гомбә жыйдык, әмма эссе булгангамы кvбесе кортлы һәм бик зурлар булдылар. Яна чыкканнары бик аз иде. Шулай да сак булырга кирәк: таныш булмаганнарын, картайганнарын, кортлыларын жыярга кирәкми. Юл яннарыннан гомбә жыярга ярамаганлыгы турында катгый кисәтеп торалар – бу тирәләрдәгеләр агулы.       Кvп вакыт топ кагыйдәне онытып таныш булмаган гомбәләрне, агулану куркынычын онытып, жыябыз. Ә алар белән агулану тиз генә тvгел, берничә сәгатьтән яки хәтта коннән сон да кvренергә момкин, дип кисәтә aif.ru микологы Максим Дьяков та.

Симптомнар гомбә торенә һәм токсиннар торенә карап vзгәреп тора. Кайбер очракларда реакция бик тиз башлана, икенчеләрендә - ике атнага кадәр сузылырга момкин, бу аеруча vлем куркынычы булган пәрәвезчеләргә (паутинникларга) хас. Еш кына vлем очраклары аксыл поганкада һәм кайбер башка гомбәләрдә булган аматоксиннар белән бәйле. Беренче билгеләре классик азыктан агулануны хәтерләтә: кvнел болгану, диарея, температура кvтәрелv һәм салкын тию.

- Әгәр ниндидер начар симптомнар гомбә кулланганнан сон барлыкка килгән икән, шундук, әлбәттә, табибка морәжәгать итәргә кирәк. Ә мостәкыйль рәвештә эш-ләргә момкин булган беренче әйбер - ашказанын юу. Бу теләсә нинди агулану вакытында универсаль эш,-  ди миколог. Максим Дьяков шулай ук кызыл чебен гомбәсен (красный мухомор) куллануны кисәтте. Анын сvзләренчә, бу гомбәдә бернинди дә файдалы әйбер юк, ә андагы токсиннар акрынлап нерв системасын жимерә. Чебен гомбәсе vлем куркынычы салмаса да, хәтта аз гына микъдарда да сәламәтлеккә житди зыян китерергә момкин.

Гомбәләрне жыйганда сак булырга кирәк.

**Н.ХӘЛИЛ,**

**Фото - ясалма интеллект программасыннан**